Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

2024 елның 25 октябре № 4

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мамашир авыл җирлегенең Тәмәй авылында гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Тәмәй авылында 2024 елның 8 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Авыл мәчете бинасында халык җыены үткәрү.Тәмәй авылы, Ленин ур., 2А.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: " Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә , 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк кешеләрдән, 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалары булган куп балалы гаилэлэрдэн,18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, 80 һәм аннан өлкәнрәкләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2025 елда һәр бэлигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту - Мәмәшир авылының урам-юл челтәренә вак таш салу, ремонтлау, карап тоту,вак таш сатып алу,автомобиль күперен ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (тирәннән суырта торган насослар һәм электр җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру, Тәмәй авылын су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Тәмәй авылында урам яктыртуны көйләү өчен, урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, ремонтлау);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Тәмәй авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре),
(спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазландыру, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, җәен территориянең печәнен чабу, материаллар сатып алу һәм ташу);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантлары һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

“ ӘЙЕ “ « КАРШЫ"»

3.Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) хәл итәргә кирәк.

4. Халык җыенын Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты оештыра.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мамашир авыл җирлеге башлыгы И.Г Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702